**Кукмара муниципаль районы**
**Зур Кукмара авыл җирлеге Советы**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2021 елның 02 декабре, № 42**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлары, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән тыш, 2022 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авылы территориясенең Урман урамы чикләрендәге бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 14 850 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

1. Зур Кукмара авылының Урман урамын асфальтлау, экспертиза ясау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

3. Әлеге карарны Зур Кукмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмати-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара
авыл җирлеге башлыгы
_______________ Р Р. Хәнәфиев.